| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| №1 | 01.10.2019 ел |

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Юртау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 33 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге территориясендә түләү мәҗбүри булган җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

- балалар лагерьларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,01%;

- җирле үзидарә органы тарафыннан карьерларны эшкәртү өчен билгеләнгән һәм файдаланылучы (гомуми киң таралган файдалы казылмаларны казып алу) җир кишәрлекләренә карата - 0,03%;

- 1-3 категорияле гомуми файдаланылудагы автомобиль юлларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә бирелә торган җир кишәрлекләренә карата - 0,05%;

- кунакханәләр урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,1%;

- бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә, шулай ук дача, бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре составында булган җир кишәрлекләренә карата - 0,3%;

- күп катлы торак төзелеше, шәхси торак төзелеше йортларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренә, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып бару өчен җир кишәрлекләренә карата - 0,15%;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә карата - 0,3%;

- саклануны тәэмин итү, иминлек һәм таможня ихтыяҗы өчен Россия Федерациясе законнарын нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,3%;

- мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин ителеш, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать, дини объектларның административ һәм офис биналарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,4%;

- җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сатып җибәрү һәм әзерләү коырлмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,0%;

- сәүдә, җәмәгать тукланыуы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,2%;

- авыл хуҗалыгы җитештерүендә файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы файдаланылуы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,5%;

- гаражлар һәм автомобиль кую урыннарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,5%;

- башка җир кишәрлекләренә карата - 1,5%.

3. Түбәндәге категорияләргә керүче салым түләүчеләрне җир салымы түләүдән азат итәргә:

1) гражданнарны җирләү урыннары, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары, чишмәләр, суэтем башнялары, скважиналар, һәйкәлләр, пляжлар биләгән җир кишәрлекләренә карата оешмаларны, учреждениеләрне.

2) 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкән гражданнарны;

3) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм катнашкан инвалидларны.

4) Татарстан Республикасы Җир Кодексының 32.1 маддәсе нигезендә бирелгән җирләр буенча күпбалалы гаиләләр.

4. Календарь ел салым чоры дип таныла. Календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталын салым түләүче-оешмалар өчен отчет чорлары дип билгеләргә.

5. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче, өченче квартал узу белән, узган отчет чоры артыннан килүче икенче айның 5 нче числосыннан соңармыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының ¼ е күләмендә аванс түләүләр аша гамәлгә ашырыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 5 февраленнән соңармыйча түләнә.

6. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советының 16.11.2018 елдагы "Җир салымы турында"гы №1 Карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

7. Гамәлдәге Карар 2019 елның 1 гыйнварында барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

8. Гамәлдәге Карар рәсми төстә басылырга тиеш.

Юртау авыл җирлеге Башлыгы
Минзәлә муниципаль районының
Юртау авыл җирлеге рәисе И.Ю.Кадыров